
## *Ерак Көнчыгышта эшләү – минем «тормыш мәктәбем»…*

### *(“Дәүләт хезмәткәре бүген” интервьюлар циклыннан)*

*Үзенең эше һәм дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең Автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль органы җитәкчесе Степанов Артем Юрьевич сөйли.*



- ***Артем Юрьевич, исәнмесез! Әңгәмәбезне Сезнең беренче эшегездән башларга тәкъдим итәм.***

- Хәерле көн! Минем хезмәт биографиям студент елларыннан ук башлана. Өченче курстан соң безне, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты (КДАТУ) студентларын, җитештерү практикасына юлладылар. Мин Транспорт корылмалары институтының юл фәнни-җитештерү үзәгенә (ИДНПЦ ИТС КГАСУ) лаборант булып урнаштым, анда республикадагы автомобиль юлларының сыйфатын контрольдә тоту белән шөгыльләндем. 2006 елда, университетны тәмамлаганнан соң, шул ук оешмада инженер булып эшли башладым. Берникадәр вакыттан соң миңа Ерак Көнчыгышта Хабаровск шәһәрендә “Россиянең Ерак Көнчыгыш регионындагы Федераль юл агентлыгының Юл төзелеше буенча регионара дирекциясе” ФДУның тикшеренү лабораториясендә 1 нче категорияле инженер булып эшләргә тәкъдим иттеләр. Минем андагы эшем Чита-Хабаровскидагы “Амур” автоюлы төзелешенең сыйфатын контрольдә тотудан гыйбарәт иде. Туган шәһәремә әйләнеп кайтканнан соң, 2010 елда Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенә эшкә кердем.

- ***Ерак Көнчыгыштагы эшегез хакында нинди хатирәләр сакланып калды?***

- Ерак Көнчыгыш – ул эшемнең колоссаль тәҗрибәсе, хәтта һөнәри планда “тормыш мәктәбе” дип тә әйтергә була. Аз вакыт эчендә төзелеш эшләренең төп күләме үзләштерелде, ә бит Хабаровскидан Читага кадәрге трассаның озынлыгы 2000 чакрымнан артып китә. Ул чакта минем вазыйфаи

вәкаләтләрем автомобиль юлының параметрларын һәм сыйфатламаларын үлчәүдән генә гыйбарәт булмыйча, пробалар – кисемнәр алуга, кисемнәрне барлык физик-механик күрсәткечләр буенча тикшерүгә, юл “киеме”нә керүче барлык конструкцияләрне, материалларны тикшерүгә, каршылык киртәләренең һәм юл тамгаларының сыйфатын контрольдә тотуга бәйле иде. Минем карашка, төзелеш вакытларының тар булуына һәм гадәти булмаган климат шартларына карамастан, юл әйбәт, заманча һәм сыйфатлы килеп чыга иде.

***- Ә Инспекциядәге беренче вазыйфагыз нинди иде?***

- Инспекциядә мин автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча бүлекнең өлкән белгече буларак эшли башладым, аннан соң консультант вазыйфасында эшләдем, төп вазыйфалар төркеме буенча кадрлар резервына керү буенча конкурста катнаштым һәм Инспекциянең кадрлар резервына кертелдем, ә 2014 елның февраленнән Автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль орган җитәкчесе итеп билгеләндем.

***- Үзегез өчен Татарстанның иң истә кала торган кайсы объектларын билгеләп үтә алыр идегез?***

– Автомобиль юлы булсынмы ул, җир асты яки җир өсте кичүе булсынмы, күпер яки транспорт әйләнеше булсынмы, һәр объект үзенчә кызыклы. Беренче объект бигрәк тә истә калды, - “Халев ур. районында җир өсте кичүе төзелеше”, аның төзелеше башыннан алып ахырына кадәр мин күзәтү эшләре алып бардым.

Сүз дә юк, Казандагы 2013 ел Универсиадасына төзелгән барлык объектлар да бик әһәмиятле һәм кызыклы. Бигрәк тә “Казансу елгасы аша күпер реконструкциясе”н (Ленин дамбасын) билгеләп үтәсе килә. Эшләрнең күләме буенча иң зур объектларның берсе, аның составына ике җир асты кичүе, күпер һәм Ленин дамбасы үзе керә.

***- Үз бүлекчәгезнең эшен ничек бәялисез? Якын киләчәктәге планнарыгыз, нәрсәләрне камилләштерергә кирәк?***

- Автоюллар һәм юл буе төзелешен күзәтү буенча территориаль органы 2012 ел башында булдырылды. Беренче җитәкченең тәҗрибәсе һәм профессионализмы ярдәмендә безнең органның эше көйләнгән һәм тиешле дәрәҗәдә оештырылган, хезмәткәрләрнең һәркайсы үз вазыйфаларын төгәл белә. Коллективыбыз бик тату һәм бердәм, куелган бурычларны сыйфатлы итеп һәм үз вакытында башкара белә.

Киләчәктә күчмә юл лабораториясен яңартырга, составка күперләр диагностикасын кертергә иде. Шулай ук стационар лабораториягә юл тамгасының сыйфатын контрольдә тоту буенча җайланма булдырасы килә. Төзелеш һәм төзелеш материалларын куллану, төзелеш эшчәнлеге өлкәсендә норматив таләпләрне һәм документларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне башкаруның нәтиҗәлелеген арттыру максатында КДАТУ белән ТР Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән үзара бәйләнештә торуны дәвам иттерергә планлаштырабыз.

***- Артем Юрьевич, җитәкче булуы җиңелме?***

- Дөресен әйтим, моңарчы зур коллективлар белән идарә итәргә туры килмәде, иң күбе алты кеше иде. Шуңа күрә зур коллективка җитәкче булуның ничегрәк икәнен әйтә алмыйм. Хәзер дә безнең Территориаль органның коллективы зур түгел. Әмма теләсә кайсы коллективта идарә итү принциплары бер үк диярлек. Әле университетта укыганда ук мөгаллимнәребез безгә, җитәкче җиде кешедән артмаган команда белән нәтиҗәле идарә итә ала, дип әйтәләр иде.

***- Дәүләт граждан хезмәте Сезнең өчен нәрсә ул?***

- Минем өчен дәүләт граждан хезмәте – дәүләт һәм аның гражданнары алдында зур җаваплылык, безнең юлларыбызның сыйфатын, озын гомерлелеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча үз вәкаләтләремне намус белән үтәү ул.

***- Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт!***

---

Степанов Артем Юрьевичның бүләкләре:

— Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Мактау грамотасы,
— ТР ДТК Инспекциясенең Рәхмәт хаты,
— “Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш инспекторы” күкрәк билгесе.

***ТР ДТКИ матбугат хезмәте***